# “Туган ягым тарихында мәктәбемнең эзе бар” укучылар конференциясе өчен гамәли – эзләнү эше

# Авыл мәгарифе бай тарихлы (Чәчер авылында мәгариф эше)

# Тарих

- Тарих! Биш кенә хәрефле сүз булса да, үз эченә меңнәрчә-миллионнарча еллар, күпме гасырларны сыйдырган. Гомер итү башланганнан бүгенге көнгә кадәр күпме сулар аккан, күпме буыннар алышынган. Галимнәр һаман да тарихыбызны тикшереп торалар, ләкин ил тарихында байтак нәрсә безнең өчен әлегә сер булып кала бирә.

# Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк

- Тарих бит ул олы диңгез кебек вак-вак тамчылардан җыела, шул "тамчылар” ярдәмендә безнең үткәнебез, бүгенгебез һәм киләчәгебез формалаша. Ләкин, кызганыч, барлык фактлар да теркәлеп бара алмый, кайбер вакыйгалар, язылып бармау сәбәпле, вакытлар узу белән онытыла, хәтердән җуела. Шуның нәтиҗәсендә тарихыбызга зыян килә, аның бер чите кителә.
- Әйе, без дә олуг тарихыбыздан килгән хакыйкатьне, чынбарлыкны, дөреслекне белергә омтылырга, эзләнергә тиешбез.

# Чәчер авылында мәгариф эше

- **Чәчер авылында мәгариф эше Октябрь инкыйлабына кадәр үк башланып китә.**
- **1923 нче елда авылда дүртьеллык башлангыч мәктәп ачыла. Анда I сыйныфтан IV сыйныфка кадәр белем бирелгән.**
- **1928 нче елда икенче мәктәп салына. Укучылар саны бихисап күп була.**

1956 нчы елда кичке мәктәп ачыла. 5 нче сыйныфтан 8 нче сыйныфка кадәр белем бирелә, укучылар документ алып чыгалар.







Сугыштан соң, 1947 нче елда мәктәп төзелә, 0,30 га тәҗрибә участогы була.







# 1956 нчы елда кичке мәктәп ачыла. Укытучылар: Рәхимә Сабирҗанова, Светлана Җәлилова, Зиннур Галимов, Вәсимә Мофаздалова, Насыйрова, Салихова, Фәттахова булалар.







# Мәктәп кабат 1990 нчы елда ачыла. 1 нче сыйныфка 5 бала укырга керә.







2002 нче елда клуб белән янәшә яңа мәктәп төзелеп сафка баса, 2006 нчы елга кадәр дүрт укучы белем ала.





# Табигать кочагында оештырылган җәйге лагерь









# Лагерьдагы күңелле мизгелләр









# Лагерьда Чәчер авылы укытучылары да хезмәт куйган







# Балаларның ялы кызыклы, мавыктыргыч итеп оештырылган.







# Лагерьдагы күңелле мизгелләр







# Җәйге ял лагерьларында районыбызның төрле авылларыннан һәм чит төбәклərдән дә бихисап күп балалар ял иткән.





# Нурҗинан Габделгани кызы Ганиева



Мәгариф өлкәсендә 40 ел хезмәт куя. Хезмәт ветераны, мәгариф бүлегенең бик күп Мактау кәгазьләренә, медальләргә лаек була.



# Вәсимә Мофаздал кызы Мофаздалова


Мәгариф өлкәсендә 40 ел 10 ай укытучы вазифасын башкара.

Уңышлары: Татарстан Фән һәм мәгариф министрлыгы, район мәгариф бүлегенең Мактау кәгазьләре, Рәхмәт хатлары; “1941-1945 нче еллардагы Бөек Ватан сугышында намуслы хезмәте өчен” медале, “Бөек Җиңүнең 50,60,65 еллыгы” юбилей медальләре.



# Габделхәй Хади улы Хадиев

Бик күп мактау кәгазьләренә, медальләргә лаек, унынчы бишьеллык ударнигы, укытучы, бүгенге көндә авылыбыз мулласы.



# Салихов Әхмәтсафа Җаббар улы

Якташыбызга 1946 нчы елда Татарстанның атказанган укытучысы дигән мактаулы исем, ә 1950 нче елда илнең иң олы бүләге – Ленин ордены бирелә.



# Чәчер авылы мәктәбендә белем биргән мөгаллимнәр

| Тәр.№ | Укытучының исеме, фамилиясе | Туган елы | Чәчер мәктәбендә эшләгән еллары |
|---|---|---|---|
| 1. | Салихов Әхмәтсафа | 1890 | 1919-1923 |
| 2. | Ишалина Тәхия | 1900 | 1923-1932 |
| 3. | Насыйров Барый | 1910 | 1924-1934 |
| 4. | Хикмәтуллин Салих | 1910 | 1934-1936 |
| 5. | Ганиева Нурҗинан | 1913 | 1936-1972 |
| 6. | Бахманов Мирза | 1912 | 1939-1941 |
| 7. | Гыйлмуллин | 1912 | 1937-1940 |
| 8. | Әминова Мәдүнә | 1913 | 1937-1939 |
| 9. | Бәдертдинов Хәммәтдин | 1910 | 1934-1935 |
| 10. | Ракипова Мосавана | | 1936-1939 |
| 11. | Галиева Мияссәрә | 1910 | 1937-1939 |
| 12. | Усманова Рәкыя | 1905 | 1939-1942 |
| 13. | Гарданов Ягсүп | 1921 | 1939-1941 |
| 14. | Сабирова Марфа | 1910 | 1935-1940 |
| 18. | Галимов Зиннур | 1901 | 1945-1961 |
| 19. | Фәттәхов | 1926 | 1954-1955 |
| 20. | Сабирҗанова Рәхимә | 1928 | 1956-1961 |
| 21. | Мофаздалова Вәсимә | 1926 | 1956-1978 |
| 22. | Хадиев Габделхәй | 1931 | 1961-1972 |
| 23. | Насыйрова Салиха | 1925 | 1963-1969 |
| 24. | Җәлилова Светлана | 1940 | 1964-1971 |
| 25. | Суфиева Илүзә | 1971 | 1990-1993 |
| 26. | Исламова Гөлназ | 1975 | 1993-2004 |
| 27. | Хәлфетдинова Алсу | 1982 | 2004-2006 |

- Без үз Туган төбәгебез тарихын ныграк өйрәнәбез икән, аның киләчәге турында да тирәнрәк уйланырбыз дигән нигез бар. Үткәнебез турында мәгълүматлар табарга, тарихи фактларны ачарга һәркемнең кулыннан килә. Мәктәпләрдә Туган якны өйрәнү эшен тагын да киң җәелдерсәк, әлегә исән булган өлкән яшьтәге кешеләр белән очрашсак, аларның истәлекләрен һәм сөйләгәннәрен язып алсак, Туган ягыбыз безгә үзенең кабатланмас тарихы һәм матур үзенчәлекләре белән тагын да тирәнрәк ачылыр иде. Аны белү, тарихи истәлекләрне бергә туплау, саклау безгә тормышта үз урыныбызны табарга, Ватаныбызга файдалы булып үсәргә ярдәм итәр. Һәрбер яңа буынның язмышы үткән заман белән аерылгысыз бәйләнештә тора. Бүгенге материаль һәм рухи культурабызның, барлык казанышларыбыз һәм җиңүләребезнең чыганагы әнә шуннан килә.

- **Туган ягыбыз тарихында Чәчер авылы мәктәбенең тирән эзе бар.**

- Игътибарыгыз өчен
- рәхмәт